СӨЯ ГОМЕРНЕ, СӨЯ ХАЛЫКНЫ, СӨЯ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №56—57 (7229—7230) | 18 май, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

## Районга министр килде

16 майда районга ТССР авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек министры Ф.С.Сибагатуллин килде.

Ул «Алга», «Комбайн», XXI партсъезд исемендәге, «Заветы Ильича», Кузнецов исемендәге, «Россия», Хафизов исемендәге колхозларда, «Сәлчә» һәм «Төрнәс» совхозларында булып бу хуҗалыкларда терлекчелек продуктлары җитештерүнең торышы һәм язгы чәчүнең барышы белән кызыксынды. Мал караучылар, кыр эшчәннәре, белгечләр, җитәкчеләр белән очрашты.

Министрны район Советы рәисе Х. Х. Морадыймов озатып йөрде.

## Беренче миллион бар

Хуҗалыкара төзелеш оешмасының кирпеч заводы, мәгълүм булганча, быел биш миллион данә кирпеч җитештерүне максат итә. Коллектив шушы көннәрдә тәүге уңышка иреште: 13 май көнне Николай Глухов сменасы беренче миллион чиген узды.

Бу уңышта һәр 4 сменаның өлеше күп керде. Шулай да җитештерелгән кирпечнең 300 мең данәсе Олег Арбузов сменасында исәпләнә. Алар сменалар арасындагы ярышта әйдәп баралар. Ә көндәшләр бик җитди биредә. Әнә шикәр заводы эшчеләре сменасы да бик булдыклы ярышташ. Шулай булмый мөмкин дә түгел, чөнки сменалар үзләре быел 1 әр миллион данә кирпеч җитештерүне максат итәләр бит. Шулай күмәк көч белән завод икенче миллионга исәпне ачты. Бу—узган елның шул чорындагыга караганда 300 меңгә артыграк дигән сүз. Сезон башланганнан бирле 50 мең данә кирпеч яндырып төзелешкә озатылды инде.

Р. ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.

Җир аны үстерде, җир аны авылның хөрмәтле кешесе итте. Армия хезмәтеннән кайткач, типсә тимер өзәрлек Зәйдулла язмышын авыл, туган җир белән бәйләргә карар иткән иде. Ул вакыттан бирле 15—16 ел гомер үтте. Бу тынгысыз хезмәт, туктаусыз камилләшү еллары булды Зәйдулла Галиуллович Әхмәтсафин өчен. Авыр механизатор хезмәте, җирне чиксез сөю үзенең җимешләрен озак көттермәде: Зәйдулла исеме алдынгылар белән беррәттән атала башлады, рәсеме берләшмәнең Мактау тактасыннан төшмәде. Аннан ул еш кына хуҗалык механизаторлары арасындагы ярышта җиңде, республика күләмендә үткәрелгән сөрүчеләр конкурсында катнашып призлы урыннарны алган чаклары да булды. Аннары күкрәген «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медале бизәде, аннары...—хәер, барын да санап бетерү мөмкин булыр микән? Әле бит Зәйдулла Галиуллович игенчелек биографиясенә нокта куярга ашыкмый. Быел ул инде 10 ел карап йөрткән Т-150 тракторын ремонтка тапшырды, үзе шундый ук маркалы иске тракторны җыеп яңартты да гөрләп эшләп йөри. Җир әзерләүдә бик әйбәт хезмәт куйды. Хәер, аның гадәте шундый: эшкә алындымы—аны һичшиксез җиренә җиткереп, күңеленә ятышлы итеп башкара ул. Шуңа эшнең иң катлаулысына алынудан да курыкмый. Әле менә быел берләшмә яңа «ДОН-1500» комбайнын алып кайткач, игенче йөрәге җилкенеп, янә яшәреп киткәндәй булды. Ә нигә миңа сынап карамаска? Инде механизатор куәтле кыр корабын җыйды, карады, өйрәнде. Исәбе—быел башка еллардагыча азык хәзерләү техникасында түгел, нәкъ шул мәгърур машинада иген кырларын иңләү. Техниканың телен, җирнең сулышын, икмәкнең кадерен белгән Зәйдулла Галиуллович биредә дә сынатмаска тиеш.



Рәсемдә: мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмә механизаторы З. Г. Әхмәтсафин.

# Татарстан ССР Югары Советы КАРАРЫ

## Татарстан ССР Президентын сайлауны билгеләү турында

«Татарстан ССР Президентын сайлау турында» Татарстан ССР Законы һәм Татарстан ССР Конституциясе нигезендә Татарстан Совет Социалистик Республикасы Югары Советы КАРАР БИРӘ:

1. 1991 елның 12 июнендә Татарстан ССРның бөтен территориясендә Татарстан ССР Президентын сайлауны билгеләргә.

2. Татарстан ССР Президентын сайлауны әзерләүне һәм үткәрүне Татарстан ССР халык депутатларын сайлау буенча Үзәк сайлау комиссиясенә йөкләргә.

3. Татарстан ССР Югары Советы Президиумына, халык депутатларының район, шәһәр Советларына, аларның башкарма органнарына Татарстан ССР Президентын сайлауны оештыру һәм үткәрүне тәэмин итү чараларын күрергә.

4. Татарстан ССР хөкүмәтенә Татарстан ССР Президентын сайлауны үткәрүне материаль һәм финанс ягыннан тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итәргә.

Татарстан ССР Югары Советы Рәисе
М. ШӘЙМИЕВ.

## „Чәчү-91" пресс-үзәге хәбәр итә

Соңгы көннәрдә игенчеләрнең бар игътибары җирдә дым беткәнче чәчүне төгәлләүгә юнәлдерелгән. Районда сабан культуралары барлык мәйданның 73, бөртекле культуралар 89 процентында чәчелделәр.

Бәрәңге чәчүне дә тизләтергә кирәк. Әлегә ул 26,8 процент мәйданда гына башкарылды.

Хуҗалыкларның күбесе хәзер чөгендер һәм кукуруз чәчү белән мәшгульләр. Шикәр чөгендере планның 34, азык чөгендере 15 проценты күләмендә чәчелде. Кукуруз чәчелгән мәйданнар 956 гектар тәшкил итә, бу—барлык мәйданның 17 проценты кадәр.

Чәчүлекләр шытканчы һәм шыткач башкарыла торган тырмалауны мөмкин кадәр күбрәк мәйданда үтәргә кирәк. Әлегә аның беренчесе 9122, икенчесе 975 гектарда башкарылды.

Чәчүлекләрне тукландыру, су сиптерү агрегатларын эшкә җигү турында да бүгеннән уйланырга вакыт.

## ҖӘЙНЕ—ҖӘЙЛӘҮДӘ

«Татарстан» колхозы.

Колхоз савучылары өчен ул күптән гадәткә кергән инде—һәр җәйне уңайлы, заманча лагерьда үткәрәләр алар. Бу көннәрдә малларны лагерьга күчерү булды. Быел да җәйләү чоры мөмкинлекләрен кулдан ычкындырмаска ниятлиләр татарстанлылар. Терлекче кадрлар тупланган, аларга ял мөмкинлекләре тудырылган. Эш шартлары да начар түгел: саву механик юл белән үткәрелә, универсаль сөтүткәргеч, суыткыч та бар.

Ф. ВӘЛИӘХМӘТОВ.

*Безнең интервью*

## Президентыбыз кем булыр?

**Уникенче чакырылыш ТССР Югары Советының дүртенче сессиясе, элек хәбәр ителгәнчә, 12 майда эшен дәвам итте. Журналист Р. Айзатуллин ТССР халык депутаты А. Н. ЕЖОВка аның барышына кагылышлы сораулар белән мөрәҗәгать итте.**

**КОРР. Анатолий Николаевич, сессиянең икенче утырышына комментарийны сез бирерсез дип газета укучыларга хәбәр итеп куйган идек. Менә ул көн җитте.**

А. Н. Е. Бу юлы көн тәртибе азрак иде. ТССР Югары Советы Рәисе М.Ш. Шәймиев беренче көнне сессиядә катнаша алмады, Мәскәүдә иде. Анда элекке автономияле республикалар җитәкчеләреннән РСФСР Югары Советы рәисе Б. Н. Ельцин, СССР Президенты М. С. Горбачев белән Союз договорына кул кую турында сөйләшүләр алып бардылар. Минтимер Шәрипович ТССРның бу килешүгә суверен республика буларак мөстәкыйль, ягъни РСФСР составыннан тыш кул куячагын белдерде.

Бусы сүз җаеннан. Сессия 12 майда даими комиссияләрдә ТССР Президентын сайлау турында Законны тикшерде. Анда тәкъдимнәр күп һәм төрлетөрле булды. Аны тикшерү икенче көнне, 13 майда сессиядә дәвам иттерелде.

**КОРР. Президент булып кем сайлана ала инде?**

А. Н. Е. ТССР Президенты итеп 35 яшьтән 65 яшькәчә булган, кимендә соңгы ун елын республикада яшәгән, ике дәүләт телен дә белүче теләсә кем сайлана ала. Ул 5 ел срокка сайлана. Сайлаулар 12 июньдә билгеләнде.

Президентны сайлау тәртибе болай. Аны теркәлгән партияләр, җәмәгать оешмалары, хезмәт коллективлары җыелышлары, торак урыннары буенча җыеннарда кандидат күрсәтергә мөмкин. Җыелыш карары аңа 300 кеше катнашканда көченә керә.

**КОРР .Инде постка кандидатлар да күрсәтү башланды.**

А. Н. Е. Әйе, вакыт ашыктыра. 14 майда питрәчлеләр М. Ш. Шәймиев кандидатурасын күрсәттеләр. Казаннан культура институты коллективы ректор Р. К. Беляевны тәкъдим итте. Хәзер аларны яклап имза җыю бара. Кандидатка тавыш бирүгә куелу өчен 50 мең кешенең яклавы кирәк.

Кандидатлар 27 майда ТССР Югары Советы сессиясендә расланырга тиеш. Анда сайлау бюллетененә кертелү өчен депутатларның өчтән беренең яклавы таләп ителә. Бу уңайдан әйтәм, һәр депутат теләсә ничә кандидатны яклап чыгарга хокуклы.

**КОРР. Сессиядә тагын нинди мәсьәләләр каралды?**

А. Н. Е. Ул Президент сайлау уңаеннан ТССР Конституциясенә үзгәрешләр кертте. Милек турында Законның альтернатив вариантлары, халык депутатларының җирле Советлары турында Закон проекты тикшерелде. Алар өстәмә эшләү өчен 27 майдагы утырышка кичектерелде.

**КОРР. Сессия РСФСР Президентын сайлауда катнашу турында карар кабул итте..**

А. Н. Е. Фикерегезне аңлыйм. Әйе, аны халык төрлечә кабул итте. Икенче көнне, 14 майда сессия барышында ук ТССР халык депутаты Ф. Бәйрәмова сәяси ачлык игълан итте. Аны татар иҗтимагый үзәге, «Иттифак», «Азатлык» партияләре яклап чыкты. Бу карарны кире алу турында имзалар җыю оештырылды.

РСФСР Президентын сайлауда катнашу ни өчен кирәк булды соң? Халыкның күп өлешендә, бигрәк тә, рус милләтеннән булганнары арасында моңа катнашырга теләүчеләр Югары Советка телеграмма, хатлар белән мөрәҗәгать иттеләр һәм итәләр. Теләүчеләрне бу хокуктан мәхрүм итү гадел булмас, Татарстанда милләтара мөнәсәбәтләрне кискенләштерер иде.

Шуны исәпкә алып, депутатларның күпчелеге әлеге карарны яклап кул күтәрде. Һәм шуны да әйтергә кирәк, бу карар ТССР өчен бернинди юридик көчкә ия була алмый.

**КОРР. Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Анатолий Николаевич.**

## Депутат ачлык игълан итә

Кабул ителгән карарда 12 июнь көнне РСФСР Президентын ТССР территориясендә сайлау турында пункт бар. Моңа кискен ризасызлык йөзеннән Татарстан Республикасының халык депутаты Фәүзия Бәйрәмова сәяси ачлык игълан итте.

—Мин моны азатлык хакында эшлим. Әлеге карарны яңадан карауны таләп итәм. Татарстанда РСФСР Президенты сайланырга тиеш түгел,—диде ул.

*КПСС райкомы пленумына*

# Активлыгыбызны арттырырга

Бүгенге көндә илдәге сәяси хәлне язгы ташкын суы шикелле итеп күз алдына китерәм: киеренке һәм болганчык замана. Төрле яктан партиягә төрле гаепләр ташлыйлар, ялалар ягалар.

Моның белән мин, әлбәттә, партиянең хаталары булмады дип әйтергә теләмим. 70 елдан артык ил белән идарә иткән КПСС-ның, объектив һәм субъектив сәбәпләр аркасында да, ялгышлары күп булды. Әмма мин ул кимчелекләрнең абсолют күпчелеген соңгылары рәтенә, субъективка кертер идем. Хикмәт шунда ки, партия җитәкчелегенең югары эшелоннарында торучы аерым шәхесләр мораль һәм әхлак нормаларын бозганнар, постларыннан явыз ниятта файдаланганнар икән, гади, гомер буе намуслы хезмәттә булганнарның моңа ни катнашы һәм нинди гаебе бар?!

Үзгәртеп кору, хәбәрдарлык һәм демократия партиягә үз эшчәнлеген тәнкыйть күзлегеннән чыгып анализларга, шәхси мәнфәгатьләрен күздә тотып, дәрәҗәле урын өчен генә партия сафларына кергән балласттан арынырга мөмкинлек тудыра. Бу мәсьәләдә мин бер нәрсәне ачык әйтәм: бүген сәяси хәл катлаулы чакта КПСС сафларыннан чыгарга теләүчеләр табыла икән, аларны үгетләү артык дип саныйм. Безгә сан артыннан куу түгел, сафларыбызның мораль, әхлак нормалары ягыннан чистарынуы мөһим: аз булса да яхшы булсын!, дигән принципны чынбарлыкта гамәлгә ашыру кирәк.

КПСС гуманлы демократик социализм идеяләрен тормышка ашыру өчен көрәшә. Ә бу идея гасырлар буе яши, хезмәт ияләренә гаделлек, тигезлек принцибын гамәлгә ашыру өчен көрәштә рухи этәргеч булып тора. Җәмгыятьтә, аерым дәүләтләрдә бу тәгълиматтан тайпылышлар булса да, социаль гаделлек массалар өчен һаман күңелләрдә саклана, һәркем омтыла торган изге максат булып калуын дәвам итә. Бу, әлбәттә, безгә кул кушырып утырырга, илдә сәяси һәм экономик хәл яхшырганны көтәргә дигән сүз түгел, марксизм-ленинизм тәгълиматын пропагандалау юнәлешендә идеология эшен туктатмаска кирәк.Һәм аның коммунистларга, партиясезләргә дә аңлаешлы, үтемле формаларын куллану, бәхәс, фикер алышу, дискуссия рәвешендә үткәрелүе мөһим.

Мин партиянең киләчәгенә, җәмгыятьтә массаларны үзенә җәлеп итүче көч булып каласына ышанам. КПСС халык интересларын күздә тотып эш итүче партия, аның максатлары халык күңеленә һәм соравына җавап бирә. Нәкъ шул һәркем өчен уртак максатлары хезмәт ияләренең, интеллигенциянең алдынгы отрядын үз сафларына тупларга мөмкинлек бирде бит. Киләчәктә дә шул гуманлылыгы белән ул массаларны, аның актив өлешен үзенә тартасына һич шикләнмим. Ләкин, кабатлап әйтәм, тормышта бу идеяләрнең үзлегеннән көчәйгәнен көтмәскә, актив позициягә басып бар коммунистларга, халыкка аңлатырга кирәк. Һәр коммунист партия язмышы турында борчыла, тирәнтен уйлана икән, шундый максатны күздә тотып эш итәргә тиеш бүген.

**А. НИКОЛАЕВ,**
шәһәрнең беренче урта мәктәбе укытучысы,
КПСС члены.




**Туган төбәгенә мәхәббәтен Рифкать Армия сафларыннан кайтып, совхозда механизатор булып калуы белән раслады.**

**Гомер буе совхозда эшләп, хәзер ялга киткән этисен алыштырды ул, һәм техниканы яхшы белүе, нинди эшкә алынуына карамастан, җиренә җиткереп, намусы кушуы буенча башкаруы белән үзен лаеклы алмаш итеп таныты.**

**Үзен җирнең чын хуҗасы итеп, зур җаваплылык тоеп эшли егет. Аңа сөрергә дә, тырмаларга да, уңышны җыеп алуда да катнашырга туры килә.**

**Бу язда Рифкать кырга чәчү агрегатларына орлык һәм башка кирәк-яраклар ташуда эшли.**

**Рәсемдә: «Төрнәс» совхозы механизаторы Р. Гыйльфанов.**

*Советлар һәм тормыш*

# Йорт салуның нәрсәсе бар...

Авылдашым Семен Антиповлар турыннан узган саен күңел сыкрап куя. 11 бала үстергән бу гаилә менә күпмедән бирле инде йорт салу белән мәшгуль. Һәм, иң кызганычы, аны өлгертеп керә алганы юк.

Хәер, бер аның гаиләсе генә йорт салу мәшәкатьләреннән интекми. Сала башлап ярты юлда тукталган йортлар бер безнең авылда гына да байтак җыела.

Хәлбуки, күңелдә урынлы сорау туа. Авылга йөз белән борылу, һәрьяклап ярдәм итү турында кайда гына сөйләнми, ниләр генә язылмый хәзер. Әмма болар еллар буена сүздән ары китә алганы юк.

Бүген авылдан яшьләр китә диеп уфтанабыз. Һәм бу хакыйкать, безнең һәм башка авыллар өчен дә уртак чир. Шул сәбәпле авылда калган егетләр дә өйләнә алмый буйдак булып яшиләр—кызлар бөтенләй юк.

Яшьләр авылдан китүнең сәбәпләре төрле. Аның берсен, әлеге дә баягы, торак белән бәйлесен алыйк. Авылыбыз урман буенда утырса да, өй салырга ярарлык урман калмады диярлек—кисеп бетерделәр инде. Бура буратсаң, нигезен салу өчен ташы, комы, цементы кирәк. Соңгысы проблемаларның да проблемасы, беркаян таба алмыйсың. Аларны җитәрлек күләмдә хәзерләгәнче бураң яртылаш черүе бик ихтимал. Алда телгә алган хуҗа—Антипов шундый агач йортны өч елдан бирле өлгертеп керә алмый.

Таш йорт салу мәшәкатьләре тагын да күбрәк. Бер йорт өлгертү өчен 10 тонна цемент, 25 мең данә силикат һәм яндырылган кирпеч кирәк. Тик аны кайдан аласың—агымдагы елда безгә нибары 5 мең данә кирпеч бүленде. Алда да күренеп тормый. Ул төзи башлаган бер йортны очлап чыгарга да җитми.Моның белән мин район Советын, аның җитәкчеләрен гаепләргә җыенмыйм, алар материалы булса бирәләр, тик үзләрендә дә фондлар юк.

Йорт салуның матди ягын алыйк. Элек такта йортлар 12 мең тора иде, хәзер 32 мең сумга җитте. Кирпеч йорт өлгертәм дисәң аннан да күбрәк акча чыгарырга кирәк. Бүгенге крестьян кулына гомере тотып карамаган күләмдәге акча ич бу. Хәрби хезмәттән кайтып өйләнгән, башка чыгарга, яңа нигез корырга теләгән кеше өчен реальме соң бу? Юк, әлбәттә. Крестьян еллар буе тамагыннан өзеп, үзен кием-салым алуда чикләп йорт өчен акча җыя. Ул гына җитми, аны салганда эшләгәне дә шунда керә. Бурычка яисә ссудага алган акчасын тагын шактый еллар хезмәт куеп түли. Бер йорт салу өчен шулай ярты гомерен хезмәт куя авыл кешесе.

Яшьләр моны күреп үсә, билгеле. Шуңа күрә кызлары мәктәпне тәмамлауга, егетләре хәрби хезмәттән соң авыл белән саубуллаша.«Норлатнефть» НГДУсы төзелгәч күп егетләр авылда торып шунда эшлиләр, торакка чиратта торалар, берничә елдан, ул җиткәч, Норлатка барып төпләнәләр: калган гомерләрен җылытылган, яктыртылган фатирларда гомер кичерәләр.

Сөйләшкәнем бар, ул яшьләрнең байтагы авылда яшәргә дә риза. Торак булганда диюем. Ләкин торак каян килсен. Колхоз төзесен, диюләре бар. Моның белән килешәм. Һәм колхоз төземичә тормый да. Бүгенге көндә «Восход» балансында 20гә якын йорт. Алар арасында агачтан, кирпечтән салынганнары, тактадан эшләнгәннәре дә бар. Аркадий Абрамовка, мәсәлән, шундый йортның берсен төзеп бетергәч үзенә сатып бирде. Ярты бәясен ул түләячәк, калганы колхоз исәбенә. Аркадий Ефимович гомер буе колхозда эшли, мондый ташламага лаек. Аларны тагын да салырга теләк зур, ләкин һаман бер үк балык башын чәйнәргә туры килә—материаллар җитми. Елына колхоз салган 1—2 йорт белән генә, кем әйтмешли, ерак китеп булмый. Бу проблеманы хәл итүдә төп юнәлеш индивидуаль торак төзүдә, минемчә. Аны киң җәелдерергә кирәк.

Колхоз идарәсе бу мәсьәләдә авыл халкына кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша. Үзендә булган материалларны биреп тора. Төзелеш материаллары кайтарганда бәянең 50 процентын гына түләтә. Тик болар авыл ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмый. Авылда торак бик аз һәм бик авырлык белән төзелә.

Авыл, аның бүгенгесе һәм киләчәге өчен дә Совет җаваплы. Әмма ул нәрсә эшли ала? Төзелеш материаллары аның кулына керми диярлек. Вакыты белән бер машина ягулык бирә алмаган дәүләт власте органының абруе да шул кадәр генә. Торак төзү, социаль объектлар булдыру мәсьәләсендә дә шул ук—булышлык итә алмыйбыз.

Кыен хәлдән ничек чыгарга? Авылны үлүдән ничек коткарып калырга? Яшьләрнең читкә китүен ничек туктатырга? Четрекле сораулар болар. Әмма хәл итә алмаслык димәс идем. Авылга материаль ярдәм мәсьәләсенә карашны тамырдан үзгәртергә кирәк. Шәһәрдә торакның күп өлеше бюджет исәбенә төзелә, эшче бернинди чыгымнарсыз әзер квартирага килеп керә. Авыл төзелеше өчен дә шундый формада средстволар бүлү, аны материаль тәэмин итү зарури. Үзе торак төзергә алынган гаиләләргә һәрьяклап булышлыкны һәм льготаларны арттыру мөһим. Колхозларга торак төзелешен киңәйтү өчен дә мөмкинлекләрне арттыру таләп ителә. Берничә ел торак, социаль объектларны коруда барлык төзүчеләрнең бар куәтен авылга юнәлдереп эшләү генә алда килеп туган проблемаларны хәл итәргә мөмкинлек бирер. Шунсыз мөмкин түгел, авыл турында бүген барлык сөйләгәннәребез элеккечә стенага борчак бәрү генә булып калачак. Ә моның нәтиҗәләре күз алдында инде: авыллар бушый, тәрәзәләр кадаклана бара, ә йөк, мәгълүм мәсәлдәгечә, һаман үз урынында.

**В. КОЛЕСНИКОВА,**
халык депутатларының Андреевка авыл Советы рәисе.

# Депутатлар игътибарына!

XXI чакырылыш халык депутатларының шәһәр Советының чираттагы, алтынчы сессиясе 28 майда МСОның кызыл почмагында 10 сәгатьтә чакырыла. Сессия көн тәртибенә түбәндәге мәсьәләләр кертү күздә тотыла:

1. Комплекслы «Сәламәтлек» программасын гамәлгә ашыру буенча халык депутатларының Норлат шәһәр Советының, шәһәр предприятиеләре һәм оешмаларының бурычлары турында. Докладчы—шәһәр Советының сәламәтлек һәм социаль тәэмин итү һәм халык мәгарифе буенча даими комиссиясе рәисе Р. Һ. Фәттахова.

2. Халык депутатларының шәһәр Советының социалистик законлылык, дәүләт һәм җәмәгать тәртибен саклау даими комиссиясе отчеты. Отчетны даими комиссия рәисе В. В. Иванов ясый.

3. Шәһәр Советы депутаты Н. А. Семенованың сайлау округында, даими комиссиядә, совет поручениеләрен үтәү буенча эше турында информациясе.

*Шәфкатьлелек*

# Кооператорлар юмартлыгы

«Меркурий» кооперативыннан (рәисе Ринат Мирзаевич Миннебаев) килгән эшчеләр больницаның ләм белән дәвалау корпусына электр үткәргечләр суздылар. Мастер Юрий Сергеевич Лихошерстов җитәкчелегендәге осталар циркуляр массаж, физиотерапия кабинетларына һәм бүтән бүлмәләргә линияләр үткәрделәр, башка җиһазларны куйдылар. Башкарган эш күләме 1,5 мең сумнан артып китте. Шунысы мөһим, шифаханәгә булгач, бу хезмәтне бушлай башкардылар алар.

Шифаханәгә игелек итүче аерым кешеләр дә бар. Каравыл Тавы авылыннан Елизавета Дмитриевна Ивашкина бездә дәваланып киткән иде. Пенсионерка карчык дәваланудан канәгать калган һәм рәхмәт йөзеннән шифаханә счетына үзе туплаган акчадан 50 сум күчергән. Ул акчага шифаханә өчен үлчәү сатып алынды.

Мондый фактлар безнең өчен беренче генә түгел инде, игелек күрсәтү очраклары аңа кадәр дә булганы бар. Бу уңайдан, сүзне йомгаклап, әлеге гуманлы адымнары өчен алда телгә алган иптәшләргә шифаханә коллективы исеменнән рәхмәт белдерәсе килә.

**А. КЛЕМЕНТЬЕВ,**
Иске Чаллы участок шифаханәсе баш врачы.

## Тулырак мәгълүмат бирәбез

Җан өшеткеч бу хәлләр бездән еракта, Иркутск каласында булган. Шулай да, милиция хезмәткәрләренең киңәше буенча, без әлеге язманы тәрҗемәләп укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәргә уйладык. Чөнки Василий Кулик кебек җир йөзен пычратучы кабәхәт җаннар кайда да очрарга мөмкин. Алай гына да түгел, үзебезнең шәһәрдә дә шуңа охшашлырак хәлләрнең булганы бар. Автозавод район эчке эшләр бүлегенең җинаятьчеләрне эзләү бүлекчәсе начальнигы Альберт Кәлимуллович Хәбибуллин менә нәрсәләр сөйләде:

—1988 елның азагы, 1989 елның башында 1 бәндә кечкенә балаларга карата бозыклыклар кылып, көчләп йөрде. Без аны биш ай буе эзләдек. Ниһаять, 1989 нчы елның мартын да җинаятьче тотылды. 1952 нче елгы К. булып чыкты ул. Үзенең дә бер баласы бар, хатыны икенчегә авырлы иде. Әшәке җан, ничә сабыйны бәхетсез итүе өстенә, үз гаиләсен дә ятим калдырды—15 елга төрмәгә утырды.

Узган ел да шундый дүрт очрак булды. Әле унҗидесе дә тулмаган яшь кенә үсмер бәләкәй кызларны чардакларга алып менеп, подъездларга сөйрәп кереп, аларга карата бозыклык кылып йөрде. Ахыр чиктә бу җинаятьче дә тотылды. Хәзер тикшеренү эшләре бара. Кызганычка каршы, быел да бер шуңа охшашлы хәл булырга өлгерде...

Альберт Кәлимуллович белән сөйләшкәндә дә, әлеге тетрәндергеч язманы тәрҗемә кылганда да бер нәрсәгә игътибар иттем: мондый җинаятьчеләрнең корбаннары—күзәтүчесез калган балалар, яисә ялгызак картлар. Хәтта җинаятьчеләрнең үз араларында да иң әшәкеләрдән саналган бу адәм актыклары, гадәттә, аз сүзле, йомыкый, күрексез, көчсез бәндәләр икән. Рәнҗетүе бик җиңел булган, үз-үзләрен саклый алмаган сабыйлар белән карт-корыны гына аулап йөрүләре шуңадыр, күрәсең. «Ата-аналар, мөмкин булган хәтле, балаларын озакка күзәтүсез калдырмасыннар иде, —ди Альберт Кәлимуллович.—Әлбәттә, үсә барган саен бала һаман әти-әнисенең итәгенә генә тагылып йөрми. Шулай да, аларны бераз кеше таный белергә, конфет биреп, уенчык күрсәтеп юхаланып маташкан «тәти» абыйларга ышанмаска, шуларга ияреп китмәскә өйрәтергә кирәк».

Заманында өй тотырып бала үстергән, ә картлык көнендә ялгыз калган әбибабайлар язмышы да уйландырырлык. Монда һаман да шул соңгы вакытта телдән төшми торган «миһербанлылык», «шәфкатьлелек» кебек сүзләрне кабатларга туры килә. Күршеңдә генә ялгызы яшәп яткан карт кешенең ара-тирә хәлен белгәләп, ярдәм иткәләп торганнан беребезнең дә тормышы кителми. Ә бу исә алар өчен, беренчедән, күңел азыгы, яшәү терәге булса, икенчедән, һәртөрле кабәхәтләр рәнҗетүенә юлыгудан саклар иде. Бер-беребезгә карата игътибарлы, мәрхәмәтле булыйк, намусларын җуйган, кешелек сыйфатын югалткан кабәхәтләрнең пычрак җинаятьләренә урын калдырмаска тырышыйк, шәһәрдәшләр!

Р. МӘГЪСҮМОВА.

# ИКЕ АЯКЛЫ ЕРТКЫЧ

Өзлексез чәйнәүче авызлардан тәмам арыган Галина Викторовна, авыл хуҗалыгы институты ашханәсе пешекчесе, берничә минутка гына тәрәзә каршына килеп басты. Урамны,«нормаль кешеләрне» күзәтеп аласы килгән иде. Хәер, монда да чәйнәүчеләр күп икән, кайсы пирожки, кайсы күмәч кисәге тоткан. Шулай да, тиз-тиз үтеп киткәнгәдер инде, туйдырырга өлгермиләр. Игътибарны җәлеп итәрдәй бер генә күренеш тә юк ичмасам. Гап-гади шәһәрнең гап-гади бер кисәге. Әнә теге йортка капиталь ремонт ясый башлауларына да биш былтыр булгай инде. Кешеләр аны, әлбәттә, шунда ук җәмагать бәдрәфенә әйләндерәләр. Әнә, бәләкәй малаен иярткән тагын бер ир-ат шунда юнәлде. Әтисе бертуктаусыз як-ягына карана, кыенсына, күрәсең. Башкасыннан оялсын иде ичмасам: үзе менә дигән итеп киенгән, ә улының өстендә иске пальто, пычрак трико. Нинди модадыр—балаларында экономиялиләр? Тәрәзә яныннан китешли Галина Викторовна инде төзелешкә якынлашып килгән бу икәүгә тагын бер кат күз төшерде һәм миенә китереп суккан сизенүдән катып калды. Менә ничә ел инде иркутскилылар , зур курку эчендә яшиләр: шәһәрдә әледән-әле кечкенә балаларны көчләү һәм ерткычларча үтерү очраклары булып тора. Хәтта бичара сабыйларның мәетләренә хәтле мәсхәрәләлиләр...

Хатын служебный бүлмәгә таба ыргылды һәм аш залына юнәлүче бухгалтерлар Андрианова белән Веселовскаяга килеп бәрелде. «Ой, Тамара, ой, Таня, бер ир-ат бәләкәй малайны төзелешкә таба алып китте, мөгаен, көчләргәдер»,—дип кычкырды ул хезмәттәшләренең кулларыннан тарта-тарта.

Тегеләре көлештеләр. «Тукта, әбәтләп алыйк инде, әкиятеңне аннары сөйләрсең». Әмма Галина Викторовна ашыга-кабалана аларга үзе күргәннәрне һәм шик-шөбһәләре турында сөйләп бирде.«Мин үзем генә дә йөгерер идем дә, киемне алыштырасым бар, өлгермим бит». Ниһаять, аның дулкынлануы хезмәттәшләренә дә күчте. Андрианова белән Веселовская төзелешкә таба йөгерделәр. Йорт янына килеп җиткәч, икесе-ике якка аерылып, тавыш-тынсыз гына тәрәзәгә күз сала-сала, бинаны әйләнә башладылар. Әмма январьның болай да караңгырак көне кичкә авышып килә иде инде, караңгы бинада һич нәрсә күреп булмый.

Тезләренә басып ярым иелгән хәлдә торучы ир-ат шәүләсен беренче булып Андрианова шәйләп алды. «Тамара, милиция чакырырга кирәк»,—дип кычкырды ул калтыранып. Ир-ат селкенмәде дә. Аны икенче тәрәзә аркылы күреп алган Веселовская: «Нишлисең син монда?»— дип кычкырды. «Хаҗәтемне үтим бит»—диде тегесе тыныч кына: «Кабәхәт, аны шундый кыяфәттә үтиләрмени!» Ир аңа җавап итеп нидер мыгырданды. Әмма Тамара: «Кешеләр, кешеләр, тотыгыз аны, ул баланы көчләде!»—ди кычкыра-кычкыра ашханәгә таба йөгерә иде инде. Шулчак залим тәрәзәдән сикереп чыкты да, Андрианованы бәреп ега язып, кача башлады. «Китә бит, китә!» Үтеп баручылардан берничә кеше аның артыннан йөгерде. Барысыннан да катырак чабучы бер егет бик тиз төркемнән аерылды да, койма аша чыгарга маташкан качкынның аягыннан эләктереп алды. Берничә секундтан ярдәм дә килеп җитте. Куа килүчеләрдән тагын берәү коймага сикереп менде һәм йодрыклап тегенең күзләренә тондырды. Мәлҗерәп төшкән качкынны коймадан сөйрәп төшерделәр дә милициягә алып киттеләр.

Төзелештә ярым шәрә малайның аңсыз гәүдәсен таптылар. Әмма ул тере иде әле. Баланы ашханәгә алып керделәр, «Ашыгыч ярдәм» чакырдылар. Малай аңына килеп ыңгырашырга тотынды: «Тимәгез, авырта, бик авырта...»

...Кулга алынучының кемлеге билгеле булгач бөтен шәһәр шаккатты. Кулик Василий Сергеевич, «Ашыгыч медицина ярдәме»нең Иркутск шәһәр станциясе линия врачы. 30 яшьтә, өйләнгән, ике баласы бар. Әтисе—профессор, биология фәннәре докторы, язучы. Әнисе—мәктәп директоры. Шундый кеше җинаятьче була ала димени!

Әмма кулга алынучы бирә башлаган күрсәтмәләрдән чәчләр үрә торырлык иде. Аның намусында 40-ка якын җинаять (көчләүләр, көчләргә маташулар, балигъ булмаганнарга карата бозыклык кылулар), шул исәптән 14(!) үтерү очрагы. Балаларны, олы яшьтәге хатыннарны, карчыкларны тормышларыннан мәхрүм иткән. Куллары белән буган, аскан, суйган. Кыз һәм ир балаларны бичараларның тавышлары, ыңгырашулары ишетелмәстәй подвалларга алып төшеп җәфалаган. Олыларга укол ясаган булып, йокы препаратлары җибәргән һәм алар белән ни теләсә, шуны кыланган...

Аның сабыйларга карата беренче «мәхәббәте» романтик төстә була. 1980 ел. Ана—24 яшь, ә кызчыкка—9. Ул аңа хатлар яза, уенчыклар бүләк итә. Романтик чор узганнан соң кызны үзенә«штаб» итеп алдан ук карап куйган чардакка чакыра башлый. Анда бик әйбәт, бергәләп уйнарбыз, сикерербез, янәсе. Әмма кыз бармый—әллә инде үзенең акылы җитә, әллә тегесенең кечкенә балаларны юмалау тәҗрибәсе җитенкерәми. Хәер, Кулик үзе бу хәлне болай аңлата: «Мин, канәгатьләнү алу өчен, партнерымның таныш түгел кеше булырга тиешлегенә төшендем».

Тиздән ул өйләнә, улы туа. Тирә-юньдәгеләр әйтүенә караганда, ир һәм ата буларак үзен бик әйбәт тота, институтта укый, буш вакытларында икенче җирләрдә акча эшли һәм... балаларны көчләп йөри. Әлегә көчли генә. Үтерү эшләренә ул соңрак, үзен 72 яшьлек карчык белән «сынап караганнан» соң керешә.

Кулик күрсәтмәләреннән: «1984 елның егерменче мартларында, иртәнге якта Тимирязев урамында минем белән бер карчык исәнләште. Сөйләшеп киттек. Мин аңа элегрәк медицина ярдәме күрсәткән булганмын икән. Сөйләшүдән аның үзе генә яшәгәнлеген аңладым һәм миндә аны көчләү уе туды. Ул сәламәтлегенә зарланды, һәм мин аңа миңгерәткеч укол ясарга уйладым. Әмма Л.ны үтерергә туры киләчәген дә яхшы аңладым, чөнки ул, һичшиксез, милициягә хәбәр итәчәк иде. Л.ның фатирына килгәч, башта мин аның кан басымын үлчәдем, аннары венасына икеләтә дозада аминазин кададым. Бу инъекциядән кеше сүлпән, хәлсез, ярым аңсыз хәлгә килә... Мин карчыкны йөзен аска каратып диванга сузып салдым да көчли башладым. Шул эш белән берәттән кулларым белән муеныннан будым...»

Кулик явыз эшләрен дәвам итә.

...Бер көнне, апасы фатирыннан кайтып килгәндә (ул анда тәүлек буе сөяркәсе белән кәеф-сафа кора) ялгызы гына уйнап йөргән кыз баланы күреп ала. 8—9 яшьләр тирәсе. Нәкъ ул яраткан яшь. Кулик бала янына килә дә качышлы уйнарга чакыра. Ялгызына гына уйнау күңелсез бит —Лариса С. риза була.

Аның мәетен күргәч, хәтта экспертлар да имәнеп китәләр. Ниләр генә кичермәгән мескен бала... Кулик күрсәтмәләреннән: «Кызый бик актив каршылык күрсәтте».

Бер айдан ул үзе медицина ярдәме күрсәтергә килгән 53 яшьлек Т. ны да шулай ук җәзалап үтерә. Әмма җәзалау кораллары бу юлы тагын да куркынычлырак була—озын пычак һәм калын агач сап.

Куликның күрсәтмәләреннән: «Мин корбаннарымның бик аз каршылык күрсәтүен тели идем. Әгәр көчлерәк чәбәләнсәләр котырып китәм. Әмма кайвакыт үзем теләгәнчә генә каршылык күрсәтсәләр дә, җан кыймый торып канәгатьләнү хисе ала алмый идем».

...Шактый дозада бирелгән йокы даруы үзенекен итте, күрәсең, 68 яшьлек И. мәлҗерәп төште. Кулик аны караватка сөйрәп китерде дә чишендерә башлады. Әмма хатын, үзен нишләтергә җыенганнарын сизеп алып, кискен хәрәкәт белән врачны өстеннән бәреп төшерде дә ишеккә таба ыргылды. Кулик аны ике сикерүдә тотып алды, идәнгә егып буа башлады. Һәм корбаны хырылдап җан биргәнчегә хәтле шулай тотып торды. Аннары кухняга кереп яхшы гына пычак сайлап алды һәм, ышанычлырак булсын өчен, мәетнең йөрәгенә кадады. Тагын ниләр кыланырга, дип уйлап-уйлап торды да, кул селтәп чыгып китте: җитәр.

...«Ашыгыч ярдәм» станциясе. Куликның дежурлык вакыты бетеп килә. Ул чираттагы корбаннарны эзләп, үзенең язу кенәгәсен актара. Чакырулар буенча медицина ярдәме күрсәтеп йөргәндә ул ялгыз хатыннарның адресларын язып бара икән. Саубуллашканда берничә көннән хәлләрен белергә керәчәге турында әйтә. «Менә! М., 1909 елгы, өе дә юл уңаенда гына... Бара бу!»

М. врачны бик кунакчыл каршылады: теге юлы бераз сөйләшеп алганда үзләренең якташлар икәнлекләрен ачыклаганнар иде бит. «Әтиегез туган якка еш кайтып йөриме соң?»—«Кая ул, вакыты җитми. Әмма бер дә онытмый. Кировоград музеенда хәтта аңа багышланган стенд та бар».—«Кит инде! Мин дә һич онытмыйм шул. Украинам төшләремә керә». —«Ягез, кәефләр, сәламәтлекләр ничек?»—«Ничек дип... Яшь бара бит инде. Начар...»—«Хәзер мин сезгә бик әйбәт укол салам. Шунда ук җиңеләер».

75 яшьлек карчыкны көчләп үтергәннән соң, кабәхәт җан әле яңа гына 2 яшь тә 7 ае тулган кыз балага кул сала...

Сабыйны ул автобус станциясеннән ерак түгел генә басып, үткән-сүткәннәрне күзәтеп торганда күреп ала. «Ой, нинди матур кызыкай! Исемең ничек синең?»— «Тата».—«Кая барасың соң, Таточка?». —«Беркая да бармыйм. Мин монда яшим»— «Уйнарга чыктыңмыни? Башта ул, саклык йөзеннән, баланы якын-тирәдәге урамтыкрыклардан әйләндерә. Таняны берәү дә эзләмәгәнлегенә ышангач, кулына күтәрә дә, алдан ук чамалап куйган подвалга алып керә. Ышанып аңа сарылган баланы подвал караңгылыгы куркытмый. Абый кеше үзен чишендергәндә дә карышмый ул. Бары: «Син мине коендырасыңмыни?»—дип кенә сорый. Көтелмәгән каты авыртудан Таня ачы тавыш белән кычкырып җибәрә. Ерткыч шунда ук аның авызын кысып тота. «Өстә, подъездга кергән җирдә кемнеңдер тавышы ишетелде, шуңа күрә мин Таняның авызыннан кулымны алмадым,—дип сөйли соңыннан Кулик.—Безне ишетүләреннән шикләнеп, баланың гәүдәсен подвал түрәнрәк күчердем. Шунда аның авызына тыгып җенси акт ясамакчы идем, әмма кызның тере түгеллеген күрдем. Үле гәүдәне шундагы ачык кладовкага ташладым да, нинидер тартмамы, чемоданмы белән каплап куйдым».

Ниндидер көчләр Куликны туган көненнән үк яшәтмәскә, һич югы, балаларда да, олыларда да аңардан курку хисе тудырырлык итеп гариплендерергә, шыксызландырырга тырышалар. Әйтерсең лә табигать бу бәндәнең үскәч нинди кыргыйлыклар, явызлыклар кыласын алдан ук белеп тора! Ул 7 айдан җитлекмәгән килеш туган. Аны веналары аша тукландыралар—организмы азыкны кабул итми. Бер айлык чагында авырлыгы ике килодан аз гына артык була. Яше тулып килгәндә, кызамык белән авырып, үлгәндә кала. Үсә төшкәч, ачык базга егылып йөзен җимерә. Ике тапкыр гепатит кичерә, ревматизм белән авырый, 12 яшенә кадәр бронхиаль астмадан буылып азаплана. Билгеле инде, зәгыйфь, ихтыярсыз булып үсә. Әмма иблис тәкъдиренә язылганны үтәми калмый, күрәсең. Василий спорт белән шөгыльләнә башлый. Бокс буенча беренче разряд ала.

(Ахыры бар).

# Җаныбыз тыныч

Быелгы яз игенчеләрне күпьяклап сынады. Яңгырын да бирде, салкынын да кызганмады, хәтта карын да күрсәтте. Шуңа да безнең «Россия» колхозы игенчеләре, чәчүгә һәрьяклап хәстәрлек белән керешсәләр дә, язгы кыр эшләрен бик кыска вакытта гына башкара алмадылар. Дөрес, район җирлегенә куеп исәпләгәндә без алдынгылар рәтендә әле. Беренчеләрдән булып бөртекле сабан культураларын чәчүне төгәлләдек, иң әүвәл чөгендергә керештек. Моңа безнең җирләрнең чагыштырмача тиз өлгерүе дә булышты, әлбәттә. Әмма иң мөһиме — шулай да кешеләр, аларның тупланганлыгы, хезмәткә омтылышында. Менә өченче ел инде бездә игенчелектә ике аренда коллективы эшли. Үзара ярышып, ярдәмләшеп эшлиләр егетләр, бу колхоз күрсәткечләрендә дә уңай чагылыш таба. Быел да звенолар арасында В. Мандрейкин егетләре өлгерлекләре белән аерылып торалар. Әлеге 2 номерлы звено бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар чәчүне быел да беренче булып төгәлләде. Чөгендергә дә әүвәл алар төштеләр. Татлы тамыр чәчүдә Владимир Петрович үзе һәм энесе Николай эшләделәр. Ул эш технология таләпләрен үтәп башкарылды, һава торышы тоткарлык ясамаганда, егетләр көнлек норманы арттырып үтәп килделәр. Ә чәчүлекләрне культивацияләүдә Валерий Саврандейкин бик тырыш хезмәт куйды. Бу звенода татлы тамыр 106 гектар исәпләнә. Мандрейкиннар бүгенге көндә аны чәчеп бетерделәр инде. Шунда ук кукуруз чәчүгә хәстәрлек башланды. Киңтән кукуруз чәчүдә эшлисе техника әзерләнде, сынап каралды, чәчү нормасы билгеләп куелды. Инде менә җиңел кулдан егетләр чәчүгә дә керештеләр. Беренче бураэнаны янә Владимир Петрович үзе үтте. Әлеге звенода кукуруз 100 гектар мәйдан били, бу — ярышташлары Перепелкин звеносыннан ике тапкыр артыграк. Шуңа егетләр беренче көннән үк удар темп алып бу культураны чәчүне дә оптималь срокларда тәмамларга ниятлиләр. Ә Николай Иванович Перепелкин звеносында җирләр соңрак өлгерү сәбәпле әле чөгендер чәчәргә керештеләр генә. Игенчеләрне шулай ук акрынлыкта гаепләрлек түгел, беренче көннәрдән үк смена нормасын арттырып үтәп килpoints. Һәр ике звено членнары турында сөйләгәндә, еш кына «ул чын игенче» дигән сүзләрне ишетергә була. Бу чынлап та шулай. Шуңа да уңыш язмышы өчен җаныбыз тыныч.

**В. ЕНДИРЯКОВ,**
«Россия» колхозы партия оешмасы секретаре.

**● *Экология: әле соң түгел***

# Без кая барабыз?

**«Су булып, анда бер балык та булмаса, мин суга ышанмаячакмын. Һавада кислород булып анда бер карлыгач та очмаса, мин һавага да ышанмаячакмын. Җәнлекләрсез урман да, урман түгел».**

**М. ПРИШВИН.**

Норлат шәһәре 2 мәктәбенең 11 нче классында нәкъ шул эпиграфка нигезләнеп конференция үткәрелде. Аңлашылганча, конференциянең темасы заманыбызның төп проблемаларыннан берсе — экология иде. Укучылар үзләренең чыгышларында галимнәрнең киләчәккә прогнозларына таянып бу киң теманың төрле аспектларына кагылдылар. Сөйләшүнең тирәге галимнәрнең киләчәккә прогнозлары иде. Ә бу прогнозлар түбәндәгеләр: планетада халык саны үсүе азык-төлек продуктлары дефицитына китерә, үсә баручы промышленность — кислоталы яңгырлар белән яный, һавада углекислый газ җыелып климатның җылынуына китерә, урманнарны кисү, җирне дөрес эшкәртмәү нәтиҗәсендә туфрак эррозия кичерә, табигатьнең үсеш закончалыклары бозылуы — табигатьтәге бәйләнешне юкка чыгара, торак пунктларының антисанитар шартлары эпидемия тарата һәм башкалар. Бу уңайдан укучылар чүплек базларына ташланучы чүп-чарлар, аларның кеше өчен зарары һәм ничек итеп аны файдалы итеп кулланырга мөмкинлеге турында чыгыш ясадылар. Шунда ук кайбер илләрдә чүп-чарны файдалы эшкә яраклаштыру мисалларын китерделәр. Мәсәлән: ФРГда чүп-чар яндыру цехы шәһәрне кайнар су һәм электроэнергия белән тәэмин итә. АКШта зарарлы калдыкларны юк итүче аерым микроблар табылган. Алар саклана торган махсус биореакторлар чүп-чар белән тукландырылып торачак.

Безнең шәһәрнең экологик хәле буенча дискуссия аеруча кызыклы булды. Әйтик, шундый сораулар — ни өчен сәүдә үзәге, элеватор ит комбинаты белән янәшә урнашканнар, ни өчен чүп түгү машиналары ял көннәрендә, бәйрәмнәрдә йөрмиләр. Шәһәрдә яшәүчеләрнең түбән культуралылыгы аркасында йорт, йорт тирәләренең пычрак хәлдә булуына көенделәр. Шунда ук чүп-чарны җыю, шәһәрне төзекләндерү буенча үзләренең тәкъдимнәрен керттеләр. Әйтик, җәйге каникуллар вакытында коммуналь хуҗалык, шәһәрне чистарту эшләренә мәктәп укучыларын тартырга кирәк, яз көннәрендә җирдәге яфракларны җыеп яндырырга түгел, түгәргә ашламалар ташудагы башбаштаклыкны (юлга түгүләр.) бетерергә, күбрәк чәчәкләр, куаклар утыртып шәһәрне яшелләндерергә һәм башкалар. Укучыларны химбаза, нефть, аммиак базасы, асфальт заводы кебек промышленность объектларының табигатьне пычратуы, газификация торбаларының сәламәтлек өчен куркынычлы һәм ямьсез урнашуы, сууткәргечтәге суның әшәкелеге аеруча борчый. Гомумән, конференциядә күтәрелгән һәр мәсьәлә уйланырга, чагыштырырга, табигатьнең иминлеген саклау юлларын эзләргә чакыра иде.

Киләчәктә җирнең аңлы, кайгыртучан чын хуҗалары булыр дип өметләнәсе килә.

**О. ХАННАНОВА,**
2 нче мәктәп укытучысы.

## *Кыр эшләре ничек бара?*

**Беренче багана — хуҗалыклар исемнәре, икенче — бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар чәчү буенча җиткерелгән план, өченче — 1991 елның 16 маена чәчелгән мәйдан (гектарларда), дүртенче — план үтәлеше (процентларда).**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Синдряков исем. | 1113 | 973 | 87 | «Чишмә» | 1165 | 1085 | 93 |
| Ульянов исем. | 1320 | 1276 | 97 | «Таң» | 390 | 390 | 100 |
| «Правда» | 960 | 460 | 48 | «Москва» | 915 | 715 | 78 |
| «Восход» | 940 | 915 | 97 | «Үрнәк» | 467 | 455 | 97 |
| Мичурин исем. | 805 | 755 | 94 | «Лесная Поляна» | 150 | 135 | 90 |
| «Россия» | 840 | 790 | 94 | «Кондырча» | 370 | 351 | 95 |
| Хафизов исем. | 492 | 356 | 72 | Кузнецов исем. | 1090 | 885 | 81 |
| «Путь к коммунизму» | 1360 | 1072 | 79 | «Заря» | 725 | 545 | 75 |
| Муса Җәлил исем. | 572 | 520 | 91 | «Чирмешән» | 340 | 291 | 86 |
| «Родина» | 714 | 411 | 58 | «Ленинский путь» | 945 | 845 | 89 |
| «Игенче» | 1168 | 1040 | 89 | «1 нче Май» | 1345 | 1035 | 77 |
| «Большевик» | 801 | 750 | 94 | «Төрнәс» совхозы | 1357 | 1055 | 78 |
| «Заветы Ильича» | 930 | 930 | 100 | «Мамык» совхозы | 860 | 860 | 100 |
| «Знамя Октября» | 990 | 990 | 100 | «Рассвет» совхозы | 1414 | 1396 | 99 |
| «Алга» | 1631 | 1448 | 89 | «Сөлчә» совхозы | 965 | 820 | 85 |
| «Комбайн» | 1520 | 1219 | 80 | Хуҗалыкара берләшмә | 250 | 202 | 81 |
| XXI партсъезд исем. | 1600 | 1600 | 100 | «Яшь көч» | 383 | 383 | 100 |
| «Татарстан» | 620 | 620 | 100 | | | | |
| «40 лет Победы» | 785 | 698 | 89 | Район буенча | 32292 | 27672 | 86 |

# Эш комплекслы бара



**«Рассвет» совхозы.** Совхоз игенчеләре бөртекле культураларны чәчүне төгәлләделәр. Хәзер төп игътибар чөгендер һәм кукуруз чәчүгә юнәлтелгән. Татлы тамыр игүдә эш комплекслы алып барыла. Бу эш белән шөгыльләнүчеләр Касыйм Сатдаров, Николай Шишков, Вәкил Габдуллин, Фәйзулла Бикиниев, Минсәлих Сатдаров һәм Вәгыйзь Гайнуллин көнлек норманы күпкә арттырып үтиләр, сыйфат мәсьәләсен дә күздән ычкындырмыйлар. Алар тырышлыгы белән чөгендер чәчү якын арада төгәлләнәчәк.

Совхозда кукуруз чәчү дә уңышлы бара. Әлеге хезмәтне үтәүче Сәлихҗан Шәрипов звеносына мактаудан кала сүз әйтерлек түгел.

Әнә шулай совхоз игенчеләре кырларда иген мул булып үссен өчен бүген тырышлык куялар.

**А. ХАРИСОВ.**

**Халык депутатларының Норлат шәһәр Советы башкарма комитеты 16 апрельдән 16 майга кадәр шәһәребездә санитар чисталык айлыгы игълан иткән иде. Депутатлар халыкка «Шәһәребез — туган йортыбыз» дигән мөрәҗәгать белән дә чыктылар. Айлык тәмамланды. Ә безгә менә нинди хат килде.**

# УРАМ АША ЧЫККАН ЧАКТА...

Кадерле редакция! Без, Пушкин урамының 30 нчы йортында яшәүчеләр сезгә үзебезнең зарыбызны язарга мәҗбүр булдык. Безнең йорт Вахитов урамы белән Пушкин урамы кисешкән урында. Шәһәрдә атналар буена бер тамчы яңгыр төшмәгән чакта да Вахитов урамының буеннан-буена яки резин итек киеп кенә үтәрлек сазлык була, яки гөрләвек булып су агып ята һәм бөтен урам иңенә тарала. Безгә каршы якта гына 1 нче балалар бакчасы урнашкан. Балаларын шунда китерүче ата-аналар да бу хәлгә нык нәфрәтләнәләр. Чөнки никадәр ерактан килсәләр дә, коры көннәрдә алар безнең йорт янына кадәр чиста-пөхтә килеш килеп җитәләр. Әмма Вахитов урамын аркылы чыкканда батмыйча-буялмыйча калмыйлар. Җитмәсә урамнан даими йөреп торган транспорт та әлеге суны-сазны чәчрәтеп үтә. Коры көннәрдә дә бу су каян чыга соң дисезме? Аның чыганагы — район культура йорты подвалында. Суны подвалдан суыртып, урамга агызалар. Ул үзе чиста су. Бәлки алар шулай дип акланырлар. Әмма нинди генә булса да, тулы бер урамны пычратырга, кешеләрнең кәефен көн дә кырырга сәбәпче ул. Әлеге суны канализация системасына кудыру мөмкин эш түгелме соң? Бәлки бутән юлы да бардыр. Ярдәм итсәгез иде. Безнең бу зарыбызга шуннан баласын йөртүче һәр ата-ана, эшкә үтеп йөрүче һәр кеше һәм янәшәсендәге йортларда яшәүчеләр дә кушыла. Сүзебезнең хаклыгына ышанасыгыз килсә, шул урамдагы теләсә кемгә мөрәҗәгать итеп карагыз! Шәһәр үзәгендәге урам икәнен дә онытмыйк! Кичләрен бию мәйданчыгына килүче яшьләр дә, культура йортының үзенә концерт-спектакльләргә баручылар да шушы ук «каршылык сызыгын» үтәргә мәҗбүрләр.

**Газетаның ярдәменә өметләнеп калабыз: 30 нчы йортта яшәүчеләр (20 имза).**

# Җиңү кулдан ычкынды

## Футбол күзәтү

— Шундый өстенлек була торып та, туп кертә алмагач... — диде мәгънәле итеп спорт сөюче Т. Камалетдинов 15 майда «Факел» һәм КамАЗ командалары уеныннан соң һәм сүз таба алмый бүленде.

— Кулдан ычкындырылган мөмкинлекләр матчы, — дип бәяләде бу уенны ветеран И. Сандлер да.

Аннан алдагы очрашуда җиңү яулаган «Факел»ның уенын карарга тамашачы күп җыелган иде. Якташларыбыз, әйтергә кирәк, шуны күреп, уенны илһамланып башлап җибәрделәр. Уенның башыннан ук инициативаны да үз кулларына алдылар, һөҗүм хәрәкәтләре җәелдерделәр. Туп көндәшләр зонасыннан чыкмады да диярлек. Шуңа күрә кунакларның уенчылары гел саклану тактикасы белән эш иттеләр. Туп безнең як кырга чыкканда да аларның уенчылары атакага ташланырга ашыкмадылар.

Факелчыларның мәйданда тулы хакимлеге уен азагына кадәр сузылды. Безнекеләр тупны кулдан бик сирәк ычкындырдылар. Флангларда үтеп тупны мәйдан уртасына күчереп карадылар, почмактан һәм штраф тибүләр дә күп булды. Беренче тайм уртасында 5 минутка якын тупны көндәшләр капкасы төбендә тәгәрәттеләр. Мондый хәлне шахматтагы чагыштыру урынлы, анда да шулай килеп чыга, дошман короле мат челтәре эчендә, тик мат юк. Футбол кырында да шундый хәл иде, тупны капкага юнәлтә алмадылар. Төгәл тибүләр дә булгалады, тик капкачы тотып ала барды, чөнки хәйләсез һәм нәкъ аңа юнәлтелгән иде туп.

Тамашачылар «Факел»ның физик һәм техник хәзерлек ягыннан да былтыргыдан күп алын, көчле булуын күрәләр, комбинацион уйнарга тырышуларын да билгелиләр. Тик ул комбинацияләрнең төгәлләнми калуы, голлар белән ныгытылмавы эчен пошыра норлатлыларның. Бу уенда да нәкъ шул хәл кабатланды, 90 минут дәвамында һөҗүм итеп тә, реаль нәтиҗәсе булмаганга очрашуның 0:0 исәбенә төгәлләнүенә канәгатьсез калдылар. Көтелгән җиңү кулдан ычкынды.

Бу очрашу ТССР чемпионатында беренче группада икенче уены иде «Факел»ның. Бу группада әлеге очрашудан соң ул ике очко туплады.

Чираттагы очрашу, стадиондагы белдерүдән аермалы буларак, 22 майда 17 сәгатьтә «Восток» (Чистай) белән булачак.

**Р. АЙЗАТУЛЛИН.**

## *19 май—В. И. Ленин исемендәге пионер оешмасы туган көн*



# Пионер ялкыны, сезгә

В. И. Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасына 69 яшь тула. Бу—бик күп кызлар, малайлар һәм аларның өлкән дусларының бәйрәме. Бәйрәм көнне иске гадәт буенча йөзләгән балалар барабан һәм быргы авазы астында пионер учагы янына җыелырлар. Биредә алар беренче пионер отрядлары төзелү тарихын, аларның беренче вожатыйлары, традицияләр турында сөйләшерләр. Үз эшләре, пионер оешмасының эшен ничек күңелле, мавыктыргыч итү турында бәхәсләшерләр.

Инде билгеле булганча, узган елның сентябрендә республикабызда мөстәкыйль, үзешчән, интернациональ оешма төзелде һәм ул яңа исем—Татарстан варис-пионерлары Союзы дигән исем алды. Димәк, оешмабыз яшь. Аңа әле 1 яшь тә юк, үзенең беренче адымнарын гына ясый. Иң мөһиме, балаларга кызыклы тормышта яшәргә, акыллы, көчле, намуслы булырга ярдәм итү өчен төзелде безнең оешма.

Варис-пионерлар Союзы—походларга йөрү һәм вакытны күңелле уздыру өчен генә түгел, ә тормышта үрнәк булу өчен дә. Пионерия—баланың олыгаюга юлы, ул башкаларга файда китерү фәне. Ул үзең һәм башкалар турында кайгырту, ярдәм итүгә әзер тору дигән сүз. Безнең лозунг: «Һәр көнне изге эш башкар!» Без ышанабыз, тик реаль эш белән генә күрсәтергә була үзеңне. Син боларның барысын да безнең Союзда табарсың.

Үзебезнең пионер оешмаларында бик күп кызыклы эшләр башкарырга өлгердек. Алар—шәфкатьлелек акциясендә катнашу, һәркем өчен Яңа ел бүләкләре хәзерләү һәм аларны ятим һәм инвалид балаларга өләшү. «Әкиятләр һәм маҗаралар дөньясында» дигән кинофестиваль үткәрелде. Анда балалар үзләре яраткан фильмнарны карый алдылар. Барлык пионер дружиналары да «Шәвәли хикмәтләре» спорт уенында, «Туган як серләре экспедициясе»ндә катнаштылар.

Балалар! Алда сезне тагын бик күп кызыклы эшләр көтә. Билгеле, без аларны олылардан башка үтәп чыга алмаячакбыз.

Кадерле балалар, вожатыйлар, пионер хәрәкәте ветераннары! Сезне барыгызны да пионерия көне белән котлыйбыз, пионер ялкыны, барлык эшләрдә дә уңышлар телибез.

**И. ЕРМИЛОВА,**
Татарстан варис-пионерлар Союзы председателе.

# Беренче тур узды

Бәгырьләргә үтәрлек көчле, кар катыш салкын җил. Үч иткәндәй учак өстендәге чәй дә кайнап чыгарга ашыкмый. Мондый көнне балалар килмәс дип пыскып янучы учак янында утырабыз. Карашларыбыз Каравыл Тавына килә торган юлда. Әнә автобусларның беренчесе күренде. Аннан икенчесе, өченчесе... Ә менә Иске Чаллы урта мәктәбе укучылары слет үтүче аланга җәяү килергә чыкканнар. Егерь янында төн үткәрү, Чирмешән елгасын көймә белән кичү. Күпме истәлек иде анда.

—Килдек, инде кире китмибез...

Шәһәрнең өченче мәктәбе укучыларының бердәм фикере шундый булды. Аңа башкалар да кушылды. Тиз арада палаткалар «аякка басты», учаклар дөрләде.

Инде ярышлар башланыр вакыт та җитте. Үч иткәндәй, җил көчәйде, тоташтан кар ява башлады. Бәлки ярышларны кичектерергәдер? Юк, шундый экстремаль шартларда ярышлар икеләтә кызыклы. Башладык! Җирәбә Егоркино мәктәбенә чыкты.

9 этаптан торган эстафетада яшь туристлар палатка кую, төеннәр бәйләү күнекмәләре буенча ярыштылар. Топографик билгеләрне тану буенча осталыкларын күрсәттеләр.

Иң яхшы вакытны өлкәннәр группасыннан Иске Чаллы, өченче мәктәп һәм «Төрнәс» мәктәбе командалары күрсәтте.

Кече группадан Вишневая Поляна (III) командасы бик яхшы нәтиҗә күрсәтте. Аннан кала—Егоркино мәктәбе командасы.

Табигатьнең кырыс холкына да карамастан, бәйгеләр кичен дә дәвам итте. Иң матур шәһәрчек һәм иң отышлы эмблема егоркинолыларда булып чыкты. Стена газетасы чыгаруда шулай ук Егоркино, фотобуклет әзерләүдә Иске Чаллы командалары җиңүче булды.

Төнлә зур учак янында агитбригадалар конкурсы башланды. Бу минутларда болытлы күк йөзе дә, бозлы яңгыр да, үзәккә үтүче җил дә онытылды.

Егоркино мәктәбе командасы иң яхшы башкаручы булып танылды. Аларның программалары тулысынча туган якка багышланган иде.

Яшь туристларның традицион район слетының I туры шулай оешкан төстә узды. Хәзерге вакытта II турга хәзерлек бара.

**Р. ИБРАҺИМОВА,**
яшь туристлар район станциясе директоры.

# «Шәвәли хикмәтләре» уены

Күптән түгел Якушкино урта мәктәбе базасында «Шәвәли хикмәтләре» куст уены булып үтте. Анда Аксумла, Салдакай, безнең мәктәптән 8 кеше катнашты. Кызганычка каршы, Илюткино мәктәбеннән безгә беркем дә килмәде.

Уенга барысы да җентекләп әзерләнгәннәр иде. Безнең куст мәктәпләре вожатыйлары физкультура дәресе җитәкчеләре белән бергә уенның программасын хәзерләделәр, туристлык кирәк-яракларын булдырдылар, балаларга задание җиткерелде. Алдан хәзерләк алып бару нәтиҗәсендә уен билгеләнгән вакытта, нәкъ 10 сәгатьтә башланды. Көн җилле, салкын булса да уенда катнашучыларга да, күзәтүчеләргә дә кызу иде. Уенның беренче этабында теоретик сораулар булды. Уен командаларны котлау һәм җыр белән башланды. Уенда катнашучыларның күкрәгендә үз командаларын белдергән эмблема бар иде. Сайлап алынгандай, һәр өч команданың да командирлары Сергей исемле иде. Менә шул өч Сергей арасында барды көчле ярышлар. Берсе дә бирешергә теләмәде. Шулай итеп «Восток» (Якушкино), «Турист» (Аксумла), «Капитошка» (Салдакай) командалары бертигез балл алдылар.

Һәр өч мәктәптән дә кергән жюри составы гадел хөкем итте. Теоретик конкурста балалар бик күп сорауларга җаваплар бирделәр. Биредә аларга экскурсияләрдә еш булу булышкандыр, мөгаен.

Шушындый «сынау»дан соң практик занятиеләр башланды. Балаларга палатка корырга һәм сүтәргә кирәк иде. Моны Салдакай мәктәбе командасы тиз башкарды. Аннан соң ике минут эчендә чыбык-чабык җыеп учак ягарга кирәк иде. Бу бурычны якушкинолылар төгәл үтәделәр. Азимут буенча хәрәкәт итеп балалар компас белән эш итә белүләрен, азимутның нәрсә икәнен төшенүләрен күрсәттеләр. Iәр өч команда да заданиене тиз үтәде һәм югары бәя алды.

Балаларны шушындый киеренке эштән соң аш көтә иде. Ашап-эчеп, ял итеп алгач ярышның өченче этабы башланды. Мәктәпнең иркен спорт залында «Күңелле старт» уеннары башланды. Заданиеләр төрле иде. Биредә тизлек, тапкырлык, һәрнәрсәне белү осталыгы сыналды. Уен башында безнең балалар бик җитез булдылар. Әмма соңрак аксумлалылар безнекеләрне куып җиттеләр һәм исәп 32:32 булды. Салдакайлылар алардан 10 очкога калышты.

Нәтиҗәдә Якушкино мәктәбе командасы 110 балл җыеп беренче, Аксумла (105 балл) икенче, Салдакай командасы өченче урынга чыкты.

Якушкино урта мәктәбе командасы район ярышларында катнашу хокукын алды.

**В. ПИТУБАЕВА,**
Якушкино урта мәктәбенең мәктәптән тыш эшләрне оештыручысы.

# Отрядларда яңалык

Отряд советлары председательләренең отчетларыннан һәркем туеп беткән иде инде. Шуңа да безнең икенче мәктәпнең 6 һәм 8 класс укучылары аларны төрлеләндерергә уйладылар һәм отчет-сайлау сборларын телевизион тапшырулар формасында алып барырга булдылар. Тамашачылар нинди генә тапшыруны карамадылар. Биредә «Сер итеп, бөтен дөньяга», «Марафон-15», «Күпер», «ТЯХ», «КСН» һәм башкалар бар иде.

8 класслар арасында иң кызыклы, төрле тапшыруларны («Мәктәп телевидениесе») 8 «б» класс укучылары күрсәтте. Алар беренче урынны алдылар да. Класс сәгате аеруча кызыклы булды. Анда З. Космодемьянская, Ю. Гагатин, Д. Карбышев, Декабристларга багышланган сборлар, Калугага барганда һәм анда булган хәлләр яңадан искә алынды. «Могҗизалар кыры» уены кызыклы һәм күңелле узды. Балалар чөгендер эшләгәннәрен дә искә төшерделәр, яхшы укучыларны мактадылар, ялкауларны утлы табага бастырдылар.

6 нчы классларның чыгышлары концертны хәтерләтә иде. Биредә 6 «а» классы җиңеп чыкты.

Бәлки барысы да без уйлаганча ук булмагандыр да. Ләкин без отчетларны шул формада уздырырга булдык.

**Г. НИКИТИНА.**
2 нче мәктәп.

# Яңа журнал—„Салават күпере"

Кадерле балалар!

Хөрмәтле әти-әниләр!

«Салават күпере» журналы сезгә шатлыклы хәбәр җиткерә: быелның июль аеннан башлап журналны элемтә бүлекләре аша яздырып алырга була. Хәзергә ул Татарстанда гына таралачак. «Салават күпере»нә язылу инде башланды. Индекс—73953. Тираж—50 мең. Журнал затлы фин кәгазенә фин буяулары белән басыла. Алты айга язылу бәясе—6 сум 60 тиен.

Игътибар!

Тиражы 50 мең данә булуга, журналга язылу туктатылачак. Сабыйлар нәүмиз булып кала күрмәсен, ашыгыгыз!

# Алар өлеше

Мәктәп яны тәҗрибә участогында пионерлар тырышып эшли бездә. Алар үстергән чөгендер, кишер, кәбестә, суган, помидор, кыяр мәктәп ашханәсенә бирелә.

Хәзер тәҗрибә участогында 100 төп кура җиләге, 100 төп карлыган, 60 төп алмагач үсә. Үсентеләрне карап үстерүдә пионерлар актив катнаша.

Хәзер пионерларның аеруча мәшәкатьле чаклары. 1 июньнән эшли башлаячак «Ялкын» пионер лагерының эшен планлаштырабыз. Пионерлар—тимурчылык хәрәкәтендә дә башлап йөрүчеләр. Ялгыз картларның олы ярдәмчеләре алар. Шуңа да олылар балаларны көтеп алалар, рәхмәт әйтеп озаталар.

Озакламый җәйге каникуллар җитә. Татарстан варис пионерлары Союзы членнарын кырларда, болыннарда, бакчаларда эшләр көтә.

**Р. САДЫЙКОВА.**
Колбай Мораса урта мәктәбе.

**БЕЛДЕРҮЛӘР**

**Фома авылында бер яшьлек кара төстәге тай һәм шундый ук төстәге 2 яшьлек бия (маңгаенда агы бар) югалды. Белүчеләр булса Галимов Хатыйпка мөрәҗәгать итсеннәр.**

x x x

**Чистарту корылмаларында профилактика үткәрелү сәбәпле, дүшәмбе, 20 майда шәһәр суүткәргеч челтәренә су бирелми.**

**МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.**

Учредительләр— халык депутатларының Октябрь район Советы, КПССның партия оешмасы.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ:** 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
**ТЕЛЕФОННАР:** мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Нурзия ФӘСХЕТДИНОВА җыйды. Рима Ганиева верстка ясады. Фирдания ХУЗЯХМЕТОВА басты. Корректор— ЗӨЛФИЯ ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 56. Тираж 3411.